РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 15 ноябре Кукмара ш. № 272

«Кукмара муниципаль районының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2023 елның 14 декабрендәге 220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджетына үзгәрешләрне карап, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2024 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын copyright расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2 492 518 268,30 сум;

2) Кукмара муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 2 524 155 259,77 сум;

3) Кукмара муниципаль районы бюджеты дефициты (профициты) 31 636 991,47 сум күләмендә.

2. 2025 елга һәм 2026 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең 2025 елга фаразлана торган гомуми күләмен 2 336 401 870,00 сум һәм 2026 елга 2 268 401 790,00 сум күләмендә;

2) 2025 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 2 336 401 870,00 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 21 491 600,00 сум һәм 2026 елга 2 268 401 790,00 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 45 901 000,00 сум;

3) Кукмара муниципаль районының 2025 елга бюджет дефициты (профициты) 0 сум, 2026 елга 0 сум күләмендә.

3. Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

2024 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2025 елга һәм 2026 елга әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә.»

1) 2024 елга Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын карарга 1 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

2) 2024 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразланган керем күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

3) 2024 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне карарга 3 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

4) 2024 елга Кукмара муниципаль районы чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

5) 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирлекләр бюджетларыннан алына торган бюджетара трансфертларны әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев